РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423739, деревня Качкиново,
ул. Центральная, дом 37в,
Тел. 3-44-63

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423739, Качкын авылы,
Үзәк ур.,37в нчы йорт.
Тел.3-44-63

КАРАР

20.06.2025 ел № 10

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына вәкаләтләрне тапшыру турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Усы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советына Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

- җирлек муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү, муниципаль милек объектларын файдалануга бирү, алар белән эш итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итү буенча;
- җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан элек бирелгән вәкаләтләр буенча;
- муниципаль милектәге җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны планлаштыруны һәм оештыруны гамәлгә ашыру;
- җирлекнең муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен законнарда билгеләнгән тәртиптә бирү һәм тартып алу, шул исәптән сатып алу юлы белән дә;
- Җирлек җирләреннән файдалануга җир контролен гамәлгә ашыру;

2. Актаныш муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул иткән очракта, Актаныш муниципаль районының Усы авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Актаныш муниципаль районы Усы авыл җирлеге Советының 2006 елның 17 июнендәге 7.1 номерлы карарының 1 пунктчасының икенче абзацын һәм 2 пунктчасының 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Усы авыл җирлеге
Советы рәисе З.З.Әхмәев